ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, 1, с.Р.Азелеево,
Зеленодольский район, 422512

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯШЕЛ ҮЗӘН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
РУС ӘҖӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Үзәк ур., 1, Р. Әҗәле авылы,
Зеленодольск р., 422512

Тел.факс: (84371) 2-68-25. E-mail: Razl.Zel@tatar.ru,
www.zelenodolsk.tatarstan.ru

# БОЕРЫК

2021 елның 16 феврале №5

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Рус Әҗәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2020 елның 14 маендагы 14 номерлы Рус Әҗәле авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗәле авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ**:

1. Рус Әҗәле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 14 маендагы 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Рус Әҗәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Административ регламентны 1.2 пункт яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Муниципаль хезмәт алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба-мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча

бурычлары булмау, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш, бу хезмәт күрсәтүне алу шарты булып тора.»;

1.2 «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» дигән 2 нче графанын 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча өстәргә:

2) мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы (булуы) турында белешмә, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш.».

1.3 «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» дигән 2 нче графанын 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

5) мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш) булуы.».

1.4 3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша бирү турында запрос җибәрә:

Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматлар).

Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы (булуы) турында белешмә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрос.»

1.5 Агач һәм куакларны кисүгә, кронлаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү турында гариза (Административ регламентның 1 нче кушымтасы) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шәхси мәгълүматлар турында»гы 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законның 9 статьясы нигезендә, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.»

2. Элеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районының рәсми сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мэглумати стендларда тубәндәге адреслар буенча: Рус Әҗәле авылы, Центральная урамы, 1 йорт( җирлек хакимияте бинасы), Карашам авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга

3.Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

**Рус Әҗәле авыл**
**җирлеге башлыгы** **Г.Ф.Семахина**